**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
e-mail:Sdev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
e-mail:Sdev.La@tatar.ru

---

**2024 елның 17 апреле** **6 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим урнаштыру турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычлыгы дәрәҗәсе арту сәбәпле, «Ягын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 60-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-Х11 номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында»карары, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Лаеш муниципаль районы территориясендә махсус янгынга каршы режим урнаштыру турында» 2024 елның 16 апрелендәге 537 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 22 апреленнән 12 маена кадәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим урнаштырырга.

2. Янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда:

учак ягу, коры үлән, чүп-чар һәм каты көнкүреш калдыкларын яндыру;

янмый торган махсус савытларда (мангалларда, кыздыру урыннарында һ. б.), урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларда, балаларның ял итүен оештыру территорияләрендә, шулай ук урман массивлары белән чиктәш икътисад объектларында ризык әзерләү өчен ачык ут куллану;

урман янгыннары куркынычы янаган торак пункт территориясендә 1-3 куркыныч класслы пиротехник әйберләр куллану.

3. Тәкъдим итәргәСүзлекФигыль1. тәкъдим итү, киңәш бирү:

3.1. Биналар, корылмалар һәм ябык складлар арасындагы янгынга каршы ара чикләрендә, шулай ук торак йортлар арасындагы участокларда

янучан калдыклардан, чүп-чардан, коелган яфраклардан һәм коры үләннән чистартуны оештырырга.

Вакыты: 2024 елның апрель - май айлары.

3.2. 50 метрдан да якынрак торак пунктлар чикләрендә чүп-чар һәм коры үлән яндыруны, шулай ук салам, урып-җыю калдыкларын яндыруны һәм басуларда учаклар ягуны тыярга.

Вакыты: бөтен чор дәвамында.

3.4. Торак пунктлар территориясендә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияләр тарату юлы белән торак пунктларында профилактика эшен дәвам итәргә.

Вакыты: бөтен чор дәвамында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Девятово башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы М.Н.Ватагина